Республика Татарстан
СОВЕТ ВЕРХНЕСИМЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422068, Республика Татарстан,
с.Верхний Симет, ул. Советская, 32
тел. 45-0-19

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ СИМЕТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422068 Татарстан Республикасы,
Югары Симет авылы , Совет урамы, 32 йорт
тел. 45-0-19

e-mail: Bsim.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
19.09.2020

КАРАР
№ 8

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советының 2019 нчы елның 2 нче июлендәге 12 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 20.07.2020 ел, № 236-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 2 июлендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле тәкъдим өстәргә: "гражданнарның инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча үткәрелгән сораштыруда инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителүче муниципаль берәмлек яки аның өлешендә яшәүче уналты яшькә җиткән гражданнар катнашырга хокуклы.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында

http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/simet адресы буенча, җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Югары Симет Авыл җирлеге башлыгы И.Р.Әхмәдуллин